| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**16.11.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2179** |

Балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы «Балалар мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары турында» карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын 2021 елның 01 гыйнварыннан расларга. (1 нче кушымта)
2. Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында (2 нче кушымта).
3. 2021 елның 01 гыйнварыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында» 2019 елның 29 октябрендәге 2287 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.
4. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ, әлеге карарның 1 пунктында расланган, гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп, гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек начальнигына Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе начальнигына йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль
районы
Башкарма комитетының
карарына
1 нче кушымта
16.11.2020 ел №2179

2021 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сум | автотранспорт чарасы узган юлының бер километрына ставка, сум |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| ГАЗ «Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 151544 | 35,91 |

2 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының карары
16.11.2020 ел №2179

# Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә, гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе, муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында факттагы узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча, автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында, башкарылган автотранспорт чарасының факттагы узган юлы буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. *i*-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f_m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ - $m$ модельле автотранспорт чараларының факттагы узган юлы, километр;

$NF_{km_m}$ - балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру нормативы ставкасы бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - балаларны мәктәптән ташу өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру нормативы ставкасы бер автотранспорт чарасы өчен, сум;

$M_m$ - m төрендәге автотранспорт чаралары саны, берәмлекләрдә;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар модельләре саны.